ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

10.10.2022 ел Баулы шәһәре № 210

2023 елга Баулы муниципаль районының балаларга туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының һәм өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 31 декабрендәге 939 номерлы «Татарстан Республикасы балаларына туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен һәм Татарстан Республикасы балаларына өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында” карары, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. 2023 елга расларга:

кушымта итеп бирелә торган туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле мәгариф оешмаларында һәм Баулы муниципаль районы балаларына өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарны;

туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарга төзәтмә коэффициентны 0,65 күләмендә.

2. Баулы муниципаль районының финанс-бюджет палатасында түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә балаларга өстәмә белем бирү оешмаларын финанслауны;

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары гамәлдә булу чоры дәвамында, хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла торган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын индексацияләү белән бер үк вакытта яңадан карау.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазифаларын башкаручы -
җитәкченең беренче урынбасары И.И. Хөснуллина

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның 10  октябрендәге
номерлы карары белщн расланган

2023 елга Баулы муниципаль районының балаларга туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының һәм өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль дислокация | Норматив чыгымнар, 1 укучыга елына сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Укытуның беренче елы | Укытуның икенче елы | Укытуның өченче һәм аннан соңгы еллары |
| Сәнгать-эстетик | шәһәр җире | 7 851 | 14 539 | 17 447 |
| | авыл җире | 8 251 | 15 280 | 18 336 |
| Физкультура-спорт | шәһәр җире | 7 750 | 14 351 | 17 222 |
| | авыл җире | 8 150 | 15 093 | 18 111 |
| Техник иҗат | шәһәр җире | 8 155 | 15 101 | 18 121 |
| | авыл җире | 8 555 | 15 842 | 19 011 |
| Туристлык-туган якны өйрәнү | шәһәр җире | 7 952 | 14 726 | 17 671 |
| | авыл җире | 8 352 | 15 467 | 18 561 |
| Экологo-биологик | шәһәр җире | 7 952 | 14 726 | 17 671 |
| | авыл җире | 8 352 | 15 467 | 18 561 |
| Хәрби-патриотик | шәһәр җире | 7 952 | 14 726 | 17 671 |
| | авыл җире | 8 352 | 15 467 | 18 561 |
| Социаль-педагогик | шәһәр җире | 7 547 | 13 977 | 16 772 |
| | авыл җире | 7 948 | 14 718 | 17 661 |
| Социаль-икътисадый | шәһәр җире | 7 547 | 13 977 | 16 772 |
| | авыл җире | 7 948 | 14 718 | 17 661 |
| Табигый-фәнни | шәһәр җире | 7 952 | 14 726 | 17 671 |
| | авыл җире | 8 352 | 15 467 | 18 561 |

____________________